# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең Морза Бәрлебаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

13 нче ноябрь 2020 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 12 нче ноябрендә 10 сәгатьтә, 2020 елның 13 нче ноябрендә 09 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (бишйөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- материаллар сатып алып,су челтәрләрен ремонтлау;
- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре (Гигиена һәм эпидемиология үзәге федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесендә суны анализлау, "Санитар саклау зоналары" һәм "Эчәр су" зоналарында СанПин нормаларына экспертиза уткәрү, санитар-эпидемиология нәтиҗәсе алу);
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү».

Экономия барлыкка килгән очракта,аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 101 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -60, бу 59,4 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 60 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең Морза Бәрлебаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2.«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (бишйөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- материаллар сатып алып,су челтәрләрен ремонтлау;
- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре (Гигиена һәм эпидемиология үзәге федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесендә суны анализлау, "Санитар саклау зоналары" һәм "Эчәр су" зоналарында СанПин нормаларына экспертиза үткәрү, санитар-эпидемиология нәтиҗәсе алу);
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү».

3.«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Морза Бәрлебаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында»гы 2020 елның 13 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарын гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Ябалак авыл җирлеге Башлыгы М.Ф.Гыйзәтуллина